# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№ 2** **22.11.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Урманай авыл җирлеге
составына керүче Беренче Май торак пунктында
2020 елда гражданнарның үзара салымын
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2020 елда Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында территориясендә беренче Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Беренче май б., Югары (Верхняя) урамына вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Беренче Май бистәсендә балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу өчен материал сатып алу;
- Беренче Май бистәсендә юлларны кардан чистарту;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-423311,ТР, Азнакай районы, Урманай авылы, Татарстан ур., 15А й. (Башкарма комитет администрациясе бинасы);

-423311,ТР, Азнакай районы, Беренче Май бистәсе, Средняя ур., 14й. (Беренче Май бистәсе мәдәният йорты).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урманай авыл җирлеге Башлыгы: А.И.Закиров